**КАРАР**

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Югары Тәкермән авыл җирлеге Советы

№ 1 "18" сентябрь 2018ел

**Референдум уздыруны инициацияләү турында**

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге №7-ФЗ Федераль законның 14 статьясы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьялары, "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы №23-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 18 маддәсе, "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Югары Тәкермән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 11 нче маддәсе нигезендә, **Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Югары Тәкермән авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРА:**

1. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Югары Тәкермән авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, студентлардан тыш, 2019 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы? " дигән сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасын куярга көндезге уку формасы буенча укучылар, Россия армиясе сафларына срочная хезмәткә чакырылган гражданнар, күп балалы гаиләләрдән тыш, аларның саны торак пунктта яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артмаска тиеш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Югары Тәкермән һәм ТүбәнТәкермән авыллары эчендәге юлларга вак таш түшәү җайланмасы,
- Югары Тәкермән авылыннан җәяүлеләр өчен чыгу юлы салу.

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Акташ чишмәсен төзекләндерү,
-Түбән Тәкермән елгасы аша җәяүлеләр күпере төзү,
- Югары Тәкермән елгасы аша җәяүлеләр күпере төзү.

"ӘЙЕ" "ЮК".

3. Әлеге карар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Минзәлә муниципаль районының menselinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында http://mamadysh.tatarstan.ru урнаштырып, халыкка җиткерелергә тиеш.

Минзәлә муниципаль районы
Югары Тәкермән авыл җирлеге башлыгы: А. А. Шәрипова